ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**23.08.2017**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2246**

М. Шорин истәлегенә һәм Зеленодольск шәһәренең 85 еллыгына багышланган V Зеленодольск марафонын үткәрү турында

Физик культураны һәм спортны пропагандалау, сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыру, башка шәһәрләр һәм төбәкләрнең спорт учреждениеләре белән үзара хезмәттәшлекне оештыру, иң көчле спортчыларны ачыклау максатларында? Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. ««Маяк» СК» ДАУ базасында М. Шорин истәлегенә һәм Зеленодольск шәһәренең 85 еллыгына багышланган V Зеленодольск Марафонын уздырырга.
2. М.Шорин истәлегенә һәм Зеленодольск шәһәренең 85 еллыгына багышланган V Зеленодольск Марафонына әзерлек һәм аны үткәрү буенча чаралар планын, әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча, расларга.
3. М.Шорин истәлегенә һәм Зеленодольск шәһәренең 85 еллыгына багышланган V Зеленодольск Марафонына уздыру турындагы нигезләмәне, әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча, расларга.
4. Башкарма комитетның Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Ф. Нигъмәтуллинга әзерлек һәм чаралар үткәрүнең гомуми җитәкчелеген тәэмин итәргә.
5. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлегенә булачак чараны анонслауны һәм массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати ярдәм күрсәтүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

1 нче кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
______________ №_____________

М.Шорин истәлегенә һәм Зеленодольск шәһәренең 85 еллыгына багышланган
V Зеленодольск Марафонын әзерләү һәм уздыру чаралар
**ПЛАНЫ**

| № | Чаралар | Датасы | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Дистанцияне билгеләргә һәм әзерләргә | 15.09 | А.Н. Березинский - ««Маяк» СК» ДАУ директоры (килешү буенча)<br>Белов Е.А. - «4 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ директоры |
| 2 | Техник персонал белән тәэмин итәргә | 16.09 | Белов Е.А. - «4 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ директоры |
| 3 | Җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итәргә | 16.09 | А.Р. Ханбиков - Зеленодольск районы буенча Эчке эшләр министрлыгы бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 4 | Чарада медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә | 16.09 | Д.М. Фалина-«Ледокол» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МАУ директоры |
| 5 | ««Маяк»СК» ДАУ янындагы стадионда старт-финиш позицияләрен әзерләргә | 16.09 | А.Н. Березинский - ««Маяк»СК» ДАУ директоры (килешү буенча) |
| 6 | Чарага мәгълүмати булышлык күрсәтергә һәм фотога төшерүне тәэмин итәргә. | 16.09 | Д.С.Анисимов -ЗМР Советының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы (килешү буенча) |

2 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
____________ №____________

М.Шорин истәлегенә һәм Зеленодольск шәһәренең 85 еллыгына багышланган V Зеленодольск Марафонын уздыру турында
нигезләмә

## 1. МАКСАТЛАР ҺӘМ БУРЫЧЛАР

- сәламәтләндерү йөгерүен популярлаштыру һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;
- шәһәр һәм район халкын физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү;
- иң көчле спортчыларны һәм командаларны ачыклау;
- башка шәһәрләрнең спорт оешмалары белән хезмәттәшлек.

## 2. ҖИТӘКЧЕЛЕК

Ярышларны әзерләү һәм үткәрү белән гомуми җитәкчелекне ЗМР БК Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе , ««Маяк»СК» ДАУ башкара. Турыдан-туры үткәрү судьялар коллегиясенә йөкләнә.

## 3. ҮТКӘРҮ УРЫНЫ ҺӘМ ВАКЫТЫ

Ярышлар Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәренең «Маяк» спорт комплексы базасында 16.09.2017 уздырыла Катнашучыларны теркәү 09.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр, парад ачылышы 11.15 сәгатьтә, старт 11.30 сәгатьтә.

42 км 195 м дистанциягә старт 10.00 сәг.

## 4. КАТНАШУЧЫЛАР ҺӘМ ПРОГРАММА

Ярышлар шәхси-команда рәвешендә. Ярышларда катнашу өчен Зеленодольск муниципаль районы халкы һәм башка шәһәр спортчылары табиб рөхсәте яисә катнашучының үз сәламәтлеге өчен шәхси җаваплылыкны раслаучы карточкасында шәхси имзасы булганда рөхсәт ителә. Шәһәр (районнар) командаларында катнашучылар саны чикләнмәгән.

Дистанцияләр: 2 км 195 м, 5 км, 10 км, 20 км, 42 км 195 м.

Ярышлар 5 төркемдә уздырыла:

*1 төркем* - VIP персоннар, ветераннар, балалар - 2 км 195 м дистанция;

*2 төркем* - яшь егетләр һәм кызлар - 22 яшькә кадәр, хатыннар- 35 - 44 яшь,

хатыннар- 55 яшь һәм өлкәнрәк, ирләр - 60-69 яшь, ирләр- 70 яшь һәм аннан өлкәнрәк - 5 км дистанция;

*3 төркем* - хатыннар 23 - 34 яшь, ирләр 50 - 59 яшь - 10 км дистанция;

*4 төркем* - ирләр 23 - 34 яшь, 35 - 49 яшь - 20 км дистанция;

*5 төркем* - ирләр һәм хатыннар 18 яшь һәм аннан өлкәнрәк -42 км 195 м дистанция.

## 5. ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕ БИЛГЕЛӘҮ ҺӘМ БҮЛӘКЛӘҮ

Шәһәрнең (районның) команда урыны, яшенә һәм җенесенә карамастан, катнашучыларның иң аз сумма буенча катнашучыларның иң яхшы 5 урыны буенча билгеләнә. Үз яшь төркемнәрендә җиңүчеләр грамоталар, медальләр, призлар белән бүләкләнә. Призерлар - медальләр, грамоталар белән.

1-3 урынны алган командалар - кубоклар, тиешле дәрәҗәле дипломнар белән. Ярышларның партнерлары тарафыннан булдырылган өстәмә призлар булырга мөмкин.

## 6. ФИНАНС ЧЫГЫМНАРЫ

Ярышларга әзерләнү һәм үткәрү белән бәйле чыгымнар ЗМР БК Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе , ««Маяк»СК» ДАУ, «Зеленодольск ПКБ» ААҖ, иганәчелек ярдәме хисабына тормышка ашырыла.

## 7. ЗАЯВКАЛАР

Ярышларда катнашу өчен алдан заявкалар 2017 елның 15 сентябренә кадәр Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсенә, тел. (84371) 4-67-93 (факс), e-mail: zel_umst@mail.ru , ««Маяк»СК» ДАУ, тел. (84371) 5-16-70, 5-14-40, (факс), e-mail: zdmayak@mail.ru бирелә.